КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 февраль

г.Казань

№ 126

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Патриотик тәрбия буенча координация советын төзү турында» 2018 ел, 12 февраль, 77 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Патриотик тәрбия буенча координация советы составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Патриотик тәрбия буенча координация советын төзү турында” 2018 ел, 12 февраль, 77 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 апрель, 309 нчы, 2019 ел, 03 июнь, 463 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Патриотик тәрбия буенча координация советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Координация советы составыннан Р.Ю.Беляковны, Р.Б.Зариповны, А.Г.Синеглазованы, Р.З.Тимерҗановны чыгарырга;

Координация советы составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Кадыйров Тимур Рәфкать улын | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасарын (килешү буенча) |
| Кыямов Руфат Рифгат улын | «Татарстан Республикасы Студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы президентын (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мартынова Олеся Олеговнаны | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенең физик культура һәм спортны үстерү секторы баш киңәшчесен |
| Мөбәрәкшин Айрат Илдус улын | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасының Волонтерлар белән эшләү департаменты җитәкчесен, «Татарстан Республикасы Ихтыярыйлар мәгълүмат-ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасының башкарма директорын (килешү буенча); |

Каракулов Станислав Олегович вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының гражданлык патриотизмын үстерү һәм профилактик эш секторы мөдире»;

Кондратьев Андрей Станиславович вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты әгъзасы (килешү буенча)»;

Камалетдинов Тимур Ринат улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин